СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.12.2023 г. Зеленодольск № 361

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының «Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Зеленодольск муниципаль районы составына керә торган шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында» 2023 елның 20 июлендәге 299 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2023 елның 7 сентябрендәге 315 номерлы, 2023 елның 2 октябрендәге 325 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән)

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2004 елның 28 июлендәге«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмә нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының «Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Зеленодольск муниципаль районы составына керә торган шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында» 2023 елның 20 июлендәге 299 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2023 елның 7 сентябрендәге 315 номерлы, 2023 елның 2 октябрендәге 325 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) 5 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы , Советы Рәисе** **М. П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль районы Советының
2023 елның 28 декабрендәге
361 номерлы карарына
кушымта

«Зеленодольск муниципаль районы Советының
2023 елның 20 июлендәге
299 номелы карарына
5 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керә торган «Осиново шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге мәсьәләсе буенча үзенең вәкаләтләренең түбәндәге өлешен тапшыра:**

- юлларда чокырларны ремонтлау;
- Осиново авылына керү кесәләрен(заездных карманов) урнаштыруны;
- Осиново авылының Нагорная урамында тротуар урнаштыру.